КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 май г.Казань № 593

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында граждан оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру турында» 2014 ел, 6 февраль, 65 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында граждан оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру турында» 2014 ел, 6 февраль, 65 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 24 ноябрь, 903 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын (алга таба – запаслар) булдыруны тәэмин итүче республика башкарма хакимият органнары исемлеген расларга.»;

2 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга, «2017 елның 23 маендагы 2-4-71-24-11 номерлы»

сүзләрен «2021 елның 29 декабрендәге 2-4-71-12-11 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга, «2017 елның 23 маендагы 2-4-71-24-11 номерлы» сүзләрен «2021 елның 29 декабрендәге 2-4-71-12-11 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын (алга таба – запаслар) булдыруны тәэмин итүче Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары исемлегендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын (алга таба – запаслар) булдыруны тәэмин итүче республика башкарма хакимият органнары исемлеге»;

2 графаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика башкарма хакимият органы исеме».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин